МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**

28.04.2018

**БОЕРЫК**

№ 262

**Казан ш.**

Татарстан Республикасы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең
һәм йөк ташуның муниципальара маршрутларын
билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны һәм “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының “Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең

һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибен раслау турында” 2017 елның 14 сентябрендәге 278 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлеге башлыгы Н.Н.Доброхотов әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә тиеш.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Транспорт идарәсе башлыгы А.В. Сидоровка йөкләргә.

Министр в.б. А.Н. Усманов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының 2018 елның
28 апрелендәге 262 номерлы
боерыгы белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ДАИМИ РӘВЕШТӘ ПАССАЖИРЛАР ЙӨРТҮНЕҢ ҺӘМ ЙӨК ТАШУНЫҢ МУНИЦИПАЛЬАРА МАРШРУТЛАРЫН БИЛГЕЛӘҮ, ҮЗГӘРТҮ ҺӘМ ТУКТАТУ ТӘРТИБЕ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутларын билгеләүнең, үзгәртүнең һәм туктатуның әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутларын (алга таба – муниципальара маршрут) билгеләү, үзгәртү һәм туктату механизмын (шул исәптән, юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү, туктату турындагы гаризаларын карау тәртибен, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләүгә яисә үзгәртүгә каршы килү нигезләрен, әлеге маршрутларны туктатуга каршы килү нигезләрен) билгели.

2. Муниципальара маршрут Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) карары белән аның үз тәкъдиме буенча яисә юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның (алга таба – гариза бирүче) гаризалары буенча билгеләнә, үзгәртелә яисә туктатыла һәм Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә. Муниципальара маршрутны билгеләү, үзгәртү, туктату турында территорияләреннән муниципальара маршрут уза торган муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән килештерелгән гариза, аны бирүченең ихтыяры буенча, Министрлыкка турыдан-туры китерелә, почта белән яисә электрон имза куелган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

3. Билгеләнгән яисә үзгәртелгән муниципальара маршрутлар турында белешмәләр “Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен раслау турында” Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 26 февралендәге 74 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрына (алга таба – Реестр) кертелә һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла (алга таба – «Интернет» челтәре).

## II. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү

4. Муниципальара маршрутны билгеләү яисә үзгәртү турында карар Министрлык тарафыннан халыкның даими пассажирлар йөртүгә һәм йөк ташуга булган ихтыяҗыннан, маршрутның икътисадый нигезле булуыннан (даими пассажирлар йөртү һәм йөк ташу буенча муниципальара маршрутлар җайга салына торган тарифлар буенча билгеләнгән очракта) чыгып һәм юл шартларының юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры килүе турында территорияләреннән әлеге муниципальара маршрут уза торган муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан алынган мәгълүмат һәм юл шартларын тикшерү нигезендә кабул ителә.

5. Тәртипнең 13 пунктындагы алтынчы һәм җиденче абзацларында каралган очракларда юл шартларын тикшерү үткәрелми.

6. Муниципальара маршрут гариза бирүче тарафыннан билгеләнгән яисә үзгәртелгән очракта, гариза бирүче Министрлыкка муниципальара маршрутны билгеләү, үзгәртү турында Тәртипкә 1 нче, 2 нче кушымталар нигезендә гариза тапшыра.

7. Муниципальара маршрут билгеләү турындагы гаризага кушымта итеп аңлатма язуы бирелә, анда түбәндәгеләр булырга тиеш:

муниципальара маршрут билгеләүне нигезләү;

муниципальара маршрут буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты исемнәрен яисә әлеге муниципальара маршрут буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты урнашкан җирлекләрнең исемнәрен күрсәтеп, муниципальара маршрутның исеме;

муниципальара маршрут буенча юлдагы тукталыш пунктларының исемнәре яисә юлдагы тукталыш пунктлары урнашкан җирлекләрнең исемнәре;

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутында тукталыш пунктлары арасында транспорт чарасының хәрәкәт итүе күз алдында тотыла торган урамнарның, автомобиль юлларының, шул исәптән график шартлы билгеләрнең тукталыш пунктлары, алар арасындагы ераклык, шулай ук характерлы ориентлашу билгеләре (юллар чишелеше, тыкрыклар, тимер юл кичүләре, күперләр һ.б.) күрсәтелгән исемнәре;

муниципальара маршрутның озынлыгы;

пассажирларны утырту һәм төшерү тәртибе (даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутында билгеләнгән тукталыш пунктларында гына яисә, законнар белән тыелмаган очракларда, юл хәрәкәте кагыйдәләрендә тыелмаган башка җирдә);

муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдалану күз алдында тотылган транспорт чараларының сыйдырышлылыгы, төре, классы, экологик характеристикалары, һәрбер төрдәге транспорт чараларының максималь саны;

автобуслар хәрәкәтенең планлаштырылган расписание;

гади ширкәт шартнамәсенең күчермәсе һәм вәкаләтләрне раслый торган документ (гариза гади ширкәт шартнамәсендә вәкаләтле катнашучы тарафыннан бирелгән булса).

8. Муниципальара маршрутны үзгәртү турындагы гаризага мондый маршрутны үзгәртүне дәлилли торган аңлатма һәм әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә муниципаль маршрутны үзгәртүнең чагыштырма таблицасы кушылып бирелә.

9. Муниципальара маршрутны билгеләү яисә үзгәртү турында гаризаны һәм кушымта итеп бирелә торган белешмәләрне тапшырганнан соң 5 эш көне эчендә Министрлык әлеге гаризаны һәм аңа кушылып бирелгән документларны кабул итү турында йә, алар әлеге Тәртипнең 6, 7, 8 пунктларына туры килмәгән очракта, күрсәтелгән гаризаны һәм аңа кушылып бирелгән документларны, сәбәпләрен аңлатып, кире кайтару турында карар кабул итә.

10. Муниципальара маршрутны билгеләү яисә үзгәртү турында гариза кергән көннән алып иң күбе кырык биш көн эчендә Министрлык муниципальара маршрутны билгеләү яки үзгәртү турында яисә муниципальара маршрутны билгеләүдән, үзгәртүдән баш тарту турында карар кабул итә.

11. Муниципальара маршрутны билгеләүдән яисә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

гаризада яисә кушымта итеп бирелүче документларда белешмәләрнең дөрес бирелмәве;

башлангыч һәм соңгы тукталыш пунктларының Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 9 июнендәге 182 номерлы боерыгы белән даими пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутлары буенча башлангыч һәм (яисә) соңгы тукталыш пунктлары буларак файдалану рөхсәт ителә торган тукталыш пунктлары исемлегендә булмавы;

билгеләнә яисә үзгәртелә торган муниципальара маршрутта юл шартларын тикшерү нәтиҗәсендә аларда юл хәрәкәт иминлегенә яный торган кимчелекләр булуы ачыклану;

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган килештерүләрнең булмавы (алга таба – Федераль закон).

12. Муниципальара маршрутны билгеләү яисә үзгәртү турында гаризаны кире кайтару хакында яки гариза бирүче тәкъдиме белән муниципальара маршрутны билгеләүдән йә үзгәртүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә санала торган 5 көн эчендә Министрлык, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле хат җибәрә.

13. Муниципальара маршруттагы үзгәрешләргә түбәндәгеләр керә:

тукталыш пунктын бетерү яисә күчерү;

яңа тукталыш пункты урнаштыру;

транспорт чараларының йөрү юллары (муниципальара маршрут буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәт итә торган урамнар, автомобиль юллары) үзгәрү;

муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының классы, һәр төрдәге транспорт чараларының максималь саны үзгәрү;

муниципальара маршрутта пассажирлар утырту һәм төшерү тәртибе үзгәрү (тукталыш пунктларында гына яисә юл хәрәкәте кагыйдәләре белән тыелмаган башка җирдә);

даими пассажирлар йөртү һәм йөк ташу төре үзгәрү;

## III. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутын туктату

14. Муниципальара маршрутны туктату өчен нигезләр:

ике яисә аннан артыграк муниципальара маршрутны берләштерү;

ачык конкурсны Федераль законның 24 статьясындагы 7 өлешендә күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелмәде дип тану һәм ачык конкурсны икенче кабат үткәрмәү турында карар кабул итү;

ачык конкурс процедуралары йә торглар кабат үткәрелгән очракта Министрлыкка даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны җайга салынмый торган тарифлар буенча гамәлгә ашыру теләге булган юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан, гади ширкәт шартнамәсендә вәкаләтле катнашучылардан ачык конкурста катнашу өчен заявкалар яисә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны җайга салынмый торган тарифлар буенча гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга дәүләт контракты төзү өчен торгларда катнашуга гаризалар кермәү;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ органнарыннан әлеге муниципальара маршрутның пассажирлар йөртү иминлеген тәэмин итүнең билгеләнгән кагыйдәләренә туры килмәве турында мәгълүмат алу;

Министрлыкка муниципальара маршрут уза торган урамнарның һәм автомобиль юлларының техник торышы һәм алардагы ясалма юл корылмаларының бу муниципальара маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының максималь тулы авырлыгына һәм (яисә) габаритларына туры килмәве турында мәгълүмат керү;

тотрыклы пассажирлар агымы һәм халыкның мондый маршрутка ихтыяҗы булмау турында территорияләреннән әлеге муниципальара маршрут уза торган муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары раслаган мәгълүмат булу.

15. Муниципальара маршрут гариза бирүче тәкъдиме белән туктатылган очракта, ул муниципальара маршрутны туктату турында Министрлыкка әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендә гариза тапшыра.

16. Муниципальара маршрутны туктату турындагы гаризага Тәртипнең 14 пункты нигезендә муниципальара маршрутны туктатуны дәлилли торган аңлатма язуы кушымта итеп бирелә.

17. Муниципальара маршрутны туктату турында гаризаны һәм кушымта итеп бирелә торган белешмәләрне тапшырганнан соң 5 эш көне эчендә Министрлык әлеге гаризаны һәм аңа кушылып бирелгән документларны кабул итү турында йә, алар әлеге Тәртипнең 15, 16 пунктларына туры килмәгән очракта, күрсәтелгән гаризаны һәм аңа кушылып бирелгән документларны, сәбәпләрен аңлатып, кире кайтару турында карар кабул итә.

18. Муниципальара маршрутны туктату турында гариза кергән көннән алып иң күбе кырык биш көн эчендә Министрлык муниципальара маршрутны туктату турында яисә муниципальара туктатудан баш тарту турында карар кабул итә.

19. Тәртипнең 14 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, муниципальара маршрутны туктатудан баш тартыла.

20. Муниципальара маршрутны туктату турында гаризаны кире кайтару хакында яки гариза бирүче тәкъдиме белән муниципальара маршрутны туктатудан баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә санала торган 5 көн эчендә Министрлык, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле хат җибәрә.

21. Муниципальара маршрутны билгеләү, үзгәртү, туктату турында карарлар “Интернет” челтәренә урнаштырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм
багаж ташуның муниципальара маршрутларын
билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына
______________________________
(гариза бирүченең исеме, җавап җибәрү өчен
адресы)

**Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутын билгеләү турында гариза**

Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм йөк ташу буенча Татарстан Республикасы
_____________________________________________
(муниципаль берәмлекләр исеме)
территориясе буенча уза торган
_____________________________________________________________________,
(маршрутның исеме)
муниципальара автобус маршруты билгеләүне сорыйбыз.

Кушымта:__ б. __ н.

Гариза бирүче
____________________________ ______________ (________________________)
(вазыйфа, гариза бирүче) (имза) (тулысынча)
М.У.

Килештерелде:

____________________________ _____________ (_______________________)
(вазыйфа, җирле үзидарә органы) (имза) (тулысынча)
М.У.

Килештерелде:
(муниципальара маршрут җайга салынмый торган тимер юл кичүе аша үткән очракта)

____________________________ _____________ ( ____________________ )
(тимер юл кичүе хуҗасының вазыйфасы, исеме) (имза) (тулысынча)
М.У.

Татарстан Республикасы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм
багаж ташуның муниципальара маршрутларын
билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына
____________________________
(гариза бирүченең исеме, җавап җибәрү өчен
адресы)

**Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутын үзгәртү турында гариза**

Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм йөк ташу буенча Татарстан Республикасы
_____________________________________________
(муниципаль берәмлекләр исеме)
территориясе буенча уза торган
_____________________________________________________________________,
(маршрутның исеме)
муниципальара автобус маршрутын үзгәртүне сорыйбыз.

Кушымта:__ б. __ н.

Гариза бирүче
____________________________ ______________ (______________________)
(вазыйфа, гариза бирүче) (имза) (тулысынча)
М.У.

Килештерелде:

____________________________ ______________ (______________________)
(вазыйфа, җирле үзидарә органы) (имза) (тулысынча)
М.У.

Килештерелде:
(муниципальара маршрут җайга салынмый торган тимер юл кичүе аша үткән очракта)

____________________________ ______________ (______________________)
(тимер юл кичүе хуҗасының вазыйфасы, исеме) (имза) (тулысынча)
М.У.

Татарстан Республикасы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм
багаж ташуның муниципальара маршрутларын
билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибенә
3 нче кушымта

Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршруты

үзгәрүнең чагыштыру таблицасы

| № т/с | Муниципальара маршрутның билгеләнгән пармаметрлары | Муниципальара маршрут буенча тәкъдим ителгән үзгәрешләр | Кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып муниципальара маршрутның пармаметрлары |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| n | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм
багаж ташуның муниципальара маршрутларын
билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибенә
4 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына
______________________________
(гариза бирүченең исеме, җавап җибәрү өчен
адресы)

**Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутын туктату турында гариза**

Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм йөк ташу буенча Татарстан Республикасы
__________________________________________
(муниципаль берәмлекләр исеме)
территориясе буенча уза торган №____
____________________________________________________________,
(маршрутның исеме)
муниципальара автобус маршрутын туктатуны сорыйбыз.

Кушымта:__ б. __ н.

Гариза бирүче

| | | |
|---|---|---|
| __________________________ | ___________ | (________________________) |
| (вазыйфа, гариза бирүче) | (имза) | (тулысынча) |
| | М.У. | |

Килештерелде:

| | | |
|---|---|---|
| __________________________ | ___________ | (________________________) |
| (вазыйфа, җирле үзидарә органы) | (имза) | (тулысынча) |
| | М.У. | |